**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК**

03.03.2023 | | 205-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2021 елның 8 декабрендәге 1385-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 21 февралендәге 134-п номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 211-п номерлы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 25 февралендәге 176-п номерлы, 2022 елның 11 июлендәге 594-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр в.б. И.И.Гобәйдуллин